| | | |
|---|---|---|
| СОВЕТ ВЕРХНЕСУБАШСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ БАЛТАСИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ БАЛТАЧ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ЮГАРЫ СУБАШ АВЫЛ ЖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ |

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

«15» ноябрь 2021 г. №40

Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы «Югары Субаш авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә бюджет процессы турында» нигезләмәгә үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү хакында

Россия Федерациясе Бюджет кодексына үзгәрешләр кертү сәбәпле, Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы Югары Субаш авыл җирлеге Советы карар бирде:

1. Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы Югары Субаш авыл җирлеге Советының 2019 елның 11 ноябрендәге 122 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы « Югары Субаш авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә бюджет процессы турында» нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне һәм өстәмәләрне кертергә:

1.1 4 статьяның 9 пунктындагы 6 пунктчасына "Россия Федерациясе законнарында каралган очраклардан тыш" сүзләрен өстәргә;

1.2 4 статьяның 10 пунктындагы 3 пунктчасына "бюджетның бердәм счетында калган акчалар белән идарә итү операцияләреннән тыш" сүзләрен өстәргә;

1.3 4 статьяның 11 пунктындагы 2 пунктчасына "бюджетның бердәм счетында калган акчалар белән идарә итү операцияләреннән тыш" сүзләрен өстәргә;

1.4 28 статьяның 27 пунктына түбәндәге эчтәлекле җөмлә өстәргә: "кредит (займ, облигация займыннан тыш) буенча принципал йөкләмәләрен үтәүне тәэмин итә торган дәүләт (муниципаль) гарантиясе кредит шартнамәсендә (займ шартнамәсендә) һәм (яисә) күрсәтелгән дәүләт (муниципаль) гарантиясен бирү турында шартнамәдә кредиторның (займга бирүченең) күрсәтелгән кредит (займ) акчаларын максатчан файдалануны үз ягыннан контрольдә тоту бурычын билгеләү шарты белән бирелә.";

1.5 32 статьяның 2 пунктындагы 1 пунктчасына түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

"Россия Федерациясе милли үсешенең максатларын һәм гавами хакимият органнарының аларга ирешү буенча эшчәнлеге юнәлешләрен билгели торган документларда;".

2. Әлеге карарны "Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталы" интернет - ресурсында бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталы составында Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районының рәсми сайтында (baltasi.tatarstan.ru) һәм авыл җирлегенең махсус мәгълүмат стендларында урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә.

3. Әлеге Карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемә алам.

Югары Субаш авыл җирлеге башлыгы: А.А.Хөснетдинов